ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шилангы авылы,
422577

Тел.: (84379) 32-7-48, факс: (84379) 32-7-02.

25.12.2025 г. № № 24

На № от

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә елның «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 3700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы?»:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл төзү), дигән мәсьәлә буенча 25.12.2025 ел гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 27 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 19 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенының 18 катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен - җыенның 1 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1 . Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Берек авылында халык җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, 2026 елда 3700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл төзү) дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Берек авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В.В.Майоров